# ИРЕКЛЕ АССОЦИАТИВ ЭКСПЕРИМЕНТ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ЛИНГВИСТИК АНАЛИЗ

*Нурмөхәммәтова Р.С., Казан, КФУ, филол. фән. канд., доцент*

В статье анализируются данные свободного ассоциативного эксперимента на материале слова-стимула "бай" (богатый).

**Ключевые слова:** картина мира, языковая картина мира, свободный ассоциативный эксперимент.

Әйләнә-тирә һәм Кеше арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеген ачык чагылдыра торган төшенчәләрнең берсе – дөнья сурәте (картинасы). Дөнья сурәте – кешене әйләндереп алган чынбарлык турында билгеле бер күзаллаулар системасы. Ул дөньяның ничек корылуын, аның нинди закончалыклар буенча яшәвен, дөнья нигезендә нәрсәләр ятуын, төрле объектларның үзара мөнәсәбәтен, кешенең дөньядагы урынын һ.б. тасвирлауны күздә тота.

Кешеләр элек-электән үзләре яшәгән дөньяны аңлаешлы итәргә тырышканнар. Бу аларга үзләрен тыныч һәм уңайлы хис итү өчен кирәк булган. Бу хәзер дә шулай. Дөньяны танып белү кешенең анда торткан урынын объектив аңлауны, кешенең үз максатларыннан, ихтыяҗ һәм мәнфәгатьләреннән чыгып, әйләнә-тирәдәге әйберләргә, күренеш-вакыйгаларга үзенә бер төрле мөнәсәбәттә булуны таләп итә. Шул рәвешчә, кешедә тышкы дөньяның тулаем аңлаешлы сурәтен барлыкка китерү ихтыяҗы даими яши.

Дөнья сурәте теге яки бу халыкның, милләтнең билгеле бер чор өчен мөһим булган мәдәни кыйммәтләре һәм традицияләре нигезендә барлыкка килә һәм, иң беренче чиратта, телдә чагылыш таба. Бу исә телдә үзенчәлекле дөнья сурәте туа дигән сүз. Һәрбер табигый телгә хас үзенчәлекле дөнья сурәте бар дип санала. Шуны аңлау телдән аралашу өчен уңайлы җирлек, яки, киресенчә, төрле аңлашылмаучанлыклар тудырырга мөмкин. Шунлыктан соңгы елларда телдәге дөнья сурәтен өйрәнү төрле фәннәрдә, шул исәптән тел белемендә дә актуаль темаларның берсенә әверелде.

Телдәге дөнья сурәте – телдә чагылыш тапкан икенчел дөнья, ул кеше аңында объектив дөньяның "сыну" нәтиҗәсе. Гадәти тел ясаган дөнья сурәтендә тирәлек турында белемнәр генә түгел, бәлки әйләнә-тирә турында ялгыш карашлар да, дөньяга карата бәяләүләр, хыяллар да теркәлә. Телдәге дөнья сурәте телнең җәмгыятьтә үсеш тарихы дәвамында формалашкан чынбарлыкны кабул итү халәтен күрсәтә, диләр. Шул ук вакытта, телдәге дөнья сурәте вакыт белән бергә үзгәрә дә, һәм аның үзгәреше – дөнья үзгәрешенең чагылышы, яңа реалияләр барлыкка килү. Бу һич тә аның фәнни дөнья сурәтенә тәңгәл булуга омтылышы түгел.

Төрле милләт кешеләренең дөньяны танып белү процессында барлыкка килгән телдәге дөнья сурәте аларның телдән аралашу үзенчәлекләрен дә билгели. Боларны өйрәнүдә ассоциатив эксперимент алымын нәтиҗәле кулланырга мөмкин. Ассоциатив эксперимент кеше аңында телнең яшәү үзенчәлекләре турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу методны "аерым бер мәдәниятә һәм телгә хас, конкрет бер халыкка гына караган, акыл һәм хис ярдәмендә тупланган белемнәрне үзенә җыйган аң образларының "ассоциатив профиле" итеп карарга була" [Уфимцева 2001: 67].

Ассоциатив эксперимент кешенең, үткәндәге тәҗрибәсенә нигезләнеп, ассоциацияләрен ачыклауга юнәлдерелгән алым. Гадәттә аның өч төрен аералар: ирекле ассоциатив эксперимент; юнәлтелгән, ягъни эксперимент үткәрүче ниндидер чикләүләр куйган эксперимент; чылбырлы ассоциатив эксперимент.

Бу мәкаләдә ирекле ассоциатив эксперимент методына күбрәк тукталырбыз.

Ирекле ассоциатив эксперимент вакытында экспериментта катнашучыдан тәкъдим ителгән сүз-стимулга башына килгән иң беренче сүз (реакция) белән тиз арада җавап бирү таләп ителә. Р.М.Фрумкина фикеренчә, "башка килгән беренче сүз белән" җавап бирү күрсәтмәсе принципиаль характерда булырга тиеш [Фрумкина 2001: 191]. Сүз һәм реакция арасындагы вакыт аралыгы кимрәк булган саен, кешенең нәрсә һәм ничек язарга дип уйлап утырырга вакыты калмый, ә бу исә нәтиҗәләрнең чисталыгына китерә.

Ирекле ассоциатив эксперимент башка ассоциатив экспериментлар арасында чагыштырмача гадие, әмма шул ук вакытта ул нәтиҗәле тикшеренү ысулы да. Бу экспериментны үткәргәндә реакцияләрнең тибы, бертөрле ассоциацияләрнең ешлыгы теркәлә.

Үзенең гадилеге һәм күп мәгълүмат бирә алуы аркасында ассоциатив эксперимент психология, лингвистика, психиатрия һ.б. өлкәләрдә нәзари һәм гамәли мәсьәләләрне хәл иткәндә уңышлы файдаланыла. Хәзерге вакытта ул когнитив, лингвомәдәни һәм психолингвистик бурычларны өйрәнгәндә лингвистик тикшеренүләрдә көннән-көн ешрак кулланыла.

Ирекле ассоциатив эксперимент нәтиҗәләре буенча телләрнең ассоциатив сүзлекләре төзелә. Бу яңа тип сүзлекләр кешенең һәм аерым этносның тел аңындагы милли-мәдәни үзенчәлекләрне ачыклауны максат итеп куя. Алар буенча кеше аңында телнең яшәешен-кулланылышын да, сөйләм төзү ысулларын да күзәтергә мөмкин. Гадәттә боларны бу телдә сөйләшүчеләр үзләре белми-сизми һәм аны башка методлар ярдәмендә билгеләп тә булмый. Ирекле ассоциатив эксперимент "семантик кырлар"ның психологик эквивалентлары турында мәгълүмат туплый һәм сүзләрнең кеше психикасындагы мәгънәви бәйләнешләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Шулай ук бу нәтиҗәләргә карап, сөйләмдә сүзләрнең бер-берсе белән бәйләнеш үзенчәлекләре, сөйләм синтагматикасы турында фикер йөртергә була.

Татар тел белемендә ирекле ассоциатив эксперимент алымын ныклап куллана башлауны лингвокультурология фәне барлыкка килү белән бәйләү дөрес булыр. Соңгы елларда аерым милли-мәдәни

концептларга бәйләп үткәрелгән иркле ассоциатив эксперимент нәтиҗәләре тасвирланган кайбер фәнни мәкаләләр дөнья күрде, концептларны өйрәнеп язылган диссертацияләрдә бу нәтиҗәләргә аерым бүлек-бүлекчәләр багышлана. Болар, әлбәттә, татар теленең ассоциатив сүзлеген төзү юнәлешендә беренче адым буларак бәяләнә ала. Әмма татар тел белемендә бу өлкәдә тикшеренүләргә зур ихтыяҗ сизелә, шуны күз уңында тотып, безнең тарафтан татар яшьләре арасында иркле ассоциатив экспериментлар үткәрелә башлады.

Безнең иркле ассоциатив экспериментта КФУның Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе, тәрҗемә һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә укучы 18-24 яшьлек студентлар, магистрантлар катнашты. Алар 112 сүз-стимул белән эш итте. Бу мәкаләдә "бай" сүзе буенча ассоциатив экспериментның беренче нәтиҗәләре бирелә.

Эксперимент дәвамында алынган нәтиҗәләрне анализлауга керешкәнче, шуны искәртү урынлы булыр: сүзнең "мәдәни хәтере", беренче чиратта, тулы һәм тирән итеп лексикографик чыганакларда чагылыш таба. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә ***бай*** сыйфатының 5 мәгънәсе китерелә: 1) зур мал-мөлкәткә, матди байлыкка, күп акчага ия; 2) мул, күп микъдарда, күп санда; 3) составында файдалы матдәләре күбрәк булган катнашмалар, минераллар; 4) затлы, зиннәтле, кыйбат бәяле; 5) күп тупланган, нәтиҗәле. Шунда ук сүзнең исем мәгънәсе дә теркәлгән: зур мал-мөлкәткә, матди байлыкка ия булган кеше; байгура (ТТАС 2005: 66). Сүзлек буенча "бай" сүзенең сүзьясалыш потенциалын да күрергә мөмкин: *баету* – байлык арттыру, байлык ишәйтү; *байбикә* – бай хатыны; *байбичә* – бай хатыны; *байбәтчә* – байның буй җиткән улы (ТТАС 2005: 66); *байгура* – бай кеше; *байлык* – бай кеше булуны күрсәтеп торган халәт; күп итеп тупланган мал-мөлкәт, милек, һ.б. (ТТАС 2005: 67); *баю* – байлык туплау, бай булу һ.б. (ТТАС 2005: 78). "Синонимнар сүзлегендә" бай сүзенең 14 синонимы китерелә: мал-мөлкәтле; байлыклы; хәлле; иркен хәлле (тормышлы); дәүләтле; барлыклы; барлы; маллы; җитешле; җиткелекле; бар; мул тормышлы; таза тормышлы; мөлкәтле (СС 1999: 20). Бай сүзенең антонимнары – ярлы, хәерче (ТРАС 1997: 20), омонимы буларак диалектлардагы "ир" мәгънәсе теркәлгән (ТТОС 1997: 11). Бай сүзе татар халык мәкальләрендә дә еш очрый: һөнәр иясе *бай* булмый, *бай* булмаса да, ач булмый; ялкауга ял, йокыга *бай*; кояш агай нурга *бай*; ай моңга *бай*; тулган ай – уйга *бай*; күз *бай* булма, яз *бай* бул; бер *бай*ның йортында ике тычкан талашыр; ат – *бай*да; игенле *бай*ның исе бар, игенсез *бай*ның нисе бар; җире *бай*ның иле *бай* һ.б. (ТХМ, 1 том). Сүзлек материаллары *бай* сүзенең күләмле мәдәни эчтәлеккә ия булуын, аның татар теленең лексик составындагы лаеклы урынын һәм телдә актив кулланылышын дәлилли.

Иркле ассоциатив экспериментка килгәндә, анда 148 кеше катнашты. "Бай" сыйфаты күпчелек җавапларда *кеше* белән бәйләп карала: *кеше, мулла, президент, түрә, егет, элеккеге байлар, сәүдәгәр, коммерсант* һ.б. Мондый реакцияләр – 29,5%. Стимул-сүзгә күпсанлы реакцияләр тормышның матди ягы белән бәйле. Экспериментта катнашучыларның шактые (22%) байлык сыйфатының төп билгесе итеп *акча*ны күрсәтә. Бай булуны торакка бәйләп карау да киң таралган: торак төрле үлчәмдәге *йорт, өй, коттедж* һ.б. булырга мөмкин. Бу реакцияләр 8% тәшкил итә.

Эксперимент нәтиҗәсендә алынган ассоциацияләрне лингвистикада парадигматик һәм синтагматик ассоциацияләр дигән ике төргә бүлеп карау киң таралган. Әгәр стимул да, җавап та бер үк сүз төркеменә караса, бу парадигматик ассоциация дип атала. Ә инде стимул һәм җавап төрле сүз төркеменә нисбәтле булса, синтагматик ассоциацияләр барлыкка килә.

"Бай" сүзенең парадигматик ассоциацияләр рәтен аның синонимнары һәм антонимнары тәшкил итә. Бу реакцияләр арасында бай сүзенең антонимнары (*ярлы, хәерче, фәкыйрь, мескен*) – 12%; синонимнары (*акчалы, богатый*) – 4%. Парадигматик ассоциацияләр рәтендә *саран, рәхәт, зур, таза, авыр* кебек сыйфатларны да күрергә була.

Синтагматик ассоциацияләр арасында исем сүз төркеменә караган сүзләрнең (*кеше, мулла, президент, егет, абзый, ханнар* һ.б) күп булуы бу сүзнең исем мәгънәсендә дә йөрүе белән аңлатыла ала (бу мәгънәсе аңлатмалы сүзлектә дә теркәлгән). Бу очракта стимул сүз белән җавап арасында төр-төркемчә мөнәсәбәтләре чагылуын да күзәтергә мөмкин: бер очракта җавап, стимул белән чагыштырганда, таррак мәгънәле бер сүз (*мулла, директор, президент* һ.б.), яки стимул-сүзнең төгәлрәк атамасы була (*акчасы күп кеше, матур киенгән, малы күп кеше* һ.б.). Киресенчә дә булырга мөмкин: җавап итеп стимулга караганда киңрәк мәгънәле яки мәгънәсе аермачык булмаган сүз китерелә (*сандык, теләк, авыл, тормыш, рух, туган, халык* һ.б.).

Эксперимент нәтиҗәләрен лингвистик күзлектән тасвирлаганда реакция-җавапларның синтаксик үзенчәлекләрен билгеләп үтү дә кызыклы. Безнең күзәтүләр буенча, реакцияләр арасында бер сүз белән бирелгән җаваплар күпчелекне (85%) тәшкил итсә, сүзтезмәләр өлешенә (*элеккеге байлар, зур өй, алтын акча, зур корсаклы, алтын йорт, күп акчалы кеше* һ.б.) 11,4% җавап туры килә. Стимул сүзнең җавап белән җөмлә барлыкка китергән очрагы әлегә теркәлмәде.

Ассоциатив бәйләнешләрнең байлыгы һәм киңлеге тикшеренүчеләргә түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә: кешеләр аңында атамалар катлаулы комплексларга тупланалар, аларны ассоциатив кыр дип йөртәләр. Әлбәттә, мондый ассоциатив кыр атамалар составы ягыннан да, алар арасындагы бәйләнеше ягыннан да һәр халыкның үзенеке була. Хәтта ул төрле чорга нисбәттә бер үк халыкта да аерылырга мөмкин. Иркле ассоциатив эксперимент телдәге берәмлекләрнең ассоциатив кырларын билгеләү өчен бай материал бирә. Эксперимент нәтиҗәсендә алынган реакцияләр стимул сүзләрнең милли-мәдәни үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә.

Әле эксперимент башланды гына. Шулай да мәкалә өчен алынган “бай” сүзенә реакцияләрнең өлешчә картинасын күрү һәркемгә кызыклы булыр дип уйлыйбыз. **Бай** – акча (33), кеше (21), ярлы (11), саран (6), акчалы (5), йорт (5), хәерче (5), мулла (4), алтын (3), машина (3), акчасы күп кеше (2), зур йорт (2), коттедж (2), президент (2), сандык (2), абзый (1), авыл (1), авыр (1), акчасы күп (1), алтын акча (1), алтын йорт (1), бина (1), богатый (1), булу (1), директор (1), егет (1), зур (1), зур корсак (1), зур корсаклы (1), зур өй (1), ир (1), кибет тотучы (1), коммерсант (1), күп акча булу (1), күп акчалы кеше (1), малы күп кеше (1), матур киенгән (1), мескен (1), олырак (1), рәхәт (1), рух (1), сәүдәгәр (1), таза (1), таза, зур корсаклы кеше (1), теләк (1), тормыш (1), туган (1), түрә (1), урыс (1), фәкыйрь (1), халык (1), ханнар (1), шәхес (1), элеккеге байлар (1). 4 анкетада бу сүз-стимулга реакция бирелмәгән.

(Статья выполнена в рамках гранта РГНФ № 13-14-16014а/В)

ӘДӘБИЯТ:

1. Горошко Е.И. Интегративная модель свободного ассоциативного эксперимента, М. –Харьков: Ра-Каравелла, 2001. – 320с.
2. Мартинович Г.А. Опыт комплексного исследования данных ассоциативного эксперимента. [Интернет-ресурс. Доступ: voppsy.ru]
3. Славянский ассоциативный словарь: русский, белорусский, болгарский, украинский / Н.В.Уфимцева, Г.А.Черкасова, Ю.Н.Караулов, Е.Ф.Тарасов. – М., 2004. – 792 с.
4. Уфимцева Н.В. Сопоставительное исследование языкового сознания славян // Методологические проблемы когнитивной лингвистики. – Воронеж, 2001. – С. 65-71.
5. Фрумкина Р.М. Психолингвистика: Учеб. для студ. высш. учеб. заведений. – М.: Издательский центр «Академия», 2001. – 320 с.

ШАРТЛЫ КЫСКАРТУЛАР:

СС – Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999. – 256 б.
ТРАС – Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.Х. Татарча-русча антонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1997. – 96 б.
ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
ТТОС – Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.Х. Татар теленең омонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1997. – 96 б.
ТХМ – Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: 3 томда. – Т.1. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. – 624 б.

**ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ РЕЗУЛЬТАТОВ СВОБОДНОГО АССОЦИАТИВНОГО ЭКСПЕРИМЕНТА**

*Нурмухаметова Р.С.*

**LINGUISTIC ANALYZES OF THE RESUILS OF THE FREE ASSOCIATION EXPERIMENT**

*Nurmukhametova R.S.*

This article analyzes the free association experiment on the material of the word-stimul «bai» (rich).

**Key words:** worldview, language worldview, free association experiment.